| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАГАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАГАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 10 нче декабрь Багай авылы № 13

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районы Багай авыл җирлеге
территориясендә фейерверклар үткәрү өчен
мәйданчыклар билгеләү турында

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Федераль законның 19 нчы статьясына, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына туры китереп, Багай авыл җирлеге территориясендә салютлар һәм фейерверклар оештыру һәм үткәрү, җәмәгать урыннарында пиротехник эшләнмәләрне куллануны, халыкның иминлеген, инфраструктура объектларын тәэмин итү, массакүләм чаралар үткәрүне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Пиротехник чаралар (эшләнмәләр) куллану өчен мәйданчыклар билгеләргә (1нче кушымта).

2.Гражданнар тарафыннан көнкүреш пиротехника әйберләрен куллану буенча инструкцияне һәм белешмәлекне мәгълүмати стендларда урнаштырырга.


3.Әлеге карарны Уставта билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.


Багай авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Р. Ф. Кузнецова

Багай авыл җирлеге
Башкарма комитетының
10.12.2019 елның 13 нче карарына
1 нче кушымта

# Село Багаево




# Село Арасланово



# Деревня Салтыганово

